СОВЕТ АКТАНЫШСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
423740,село Актаныш, проспект Ленина,дом 58,тел.3-15-99

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ АКТАНЫШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
423740, Актаныш авылы, Ленин проспекты, 58 нче йорт, тел.3-15-99

**КАРАР**

№ 7 «18» МАРТ 2020 ел

**Актаныш муниципаль районы Актаныш авыл җирлеге Советының 11 сентябрь 2017 елда 23 номерлы карары белән расланган муниципаль берәмлектә муниципаль хезмәткәрләрне алу тәртибе турындагы «Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Актаныш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башкарма комитеты карары белән расланган яллаучы (эш бирүче) вәкиленең коммерциячел булмаган оешмалар (сәяси партиядән тыш) белән идарә итүдә катнашу яисә аларның коллегиаль идарә органнары составына керүгә рөхсәте Нигезләмәсенә үзгәрешләр кертү хакында**

"Коррупциягә каршы тору турында" 2008 елның 28 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон, «Коррупциягә каршы тору турында Россия Федерациясе законнары үтәлешен тикшереп торуны камилләштерү максатларында Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 30.10.2018 ел, №382-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Актаныш авыл җирлеге башкарма комитеты **КАРАР ИТТЕ**:

1. 11 сентябр 2017 елда №23 номерлы муниципаль берәмлектә муниципаль хезмәткәрләрне алу тәртибе турындагы «Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Актаныш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башкарма комитеты карары белән расланган яллаучы (эш бирүче) вәкиленең коммерциячел булмаган оешмалар (сәяси партиядән тыш) белән идарә итүдә катнашу яисә аларның коллегиаль идарә органнары составына керүгә рөхсәте Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Актаныш авыл җирлеге нигезләмәсенә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. 2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Муниципаль хезмәт узуга бәйле рәвештә муниципаль хезмәткәргә тыела:

2.1) коммерция яки коммерцияле булмаган оешма белән идарә итүдә катнашу, түбәндәге очраклардан тыш:

а) сәяси партия, һөнәр берлеге органы, шул исәптән җирле үзидарә органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында төзелгән беренчел профсоюз оешмасының сайлау органы тарафыннан, башка иҗтимагый оешманың, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативларының, күчемсез милек, милекчеләр ширкәтенең гомуми җыелышында (конференция) катнашу;

б) коммерцияле булмаган оешма белән идарә итүдә (сәяси партия, һөнәри берлек органы, шул исәптән җирле үзидарә органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында төзелгән беренчел профсоюз оешмасының сайлау органы, башка иҗтимагый оешманың, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативларының, күчемсез милек, милекчеләр ширкәтенең гомуми җыелышында катнашу (конференция),

(конференция), Россия Федерациясе субъекты законы белән билгеләнгән, яллаучы вәкиле рөхсәте белән катнашу;

в) Россия Федерациясе субъектының муниципаль берәмлекләре советында, башка муниципаль берәмлекләрнең берләшмәләрендә, шулай ук аларның идарә органнарында муниципаль берәмлек мәнфәгатьләрен түләүсез нигездә тәкъдим итү;

г) муниципаль берәмлек, муниципаль берәмлекне гамәлгә куючы (катнашучы) муниципаль берәмлек булган оешманың идарә органнарында һәм ревизия комиссиясендә оешманы гамәлгә куючының (катнашучы) вәкаләтләрен муниципаль берәмлек исеменнән гамәлгә ашыру тәртибен яки муниципаль милектәге акцияләр устав капиталындагы өлешләр белән идарә итү тәртибен билгели торган муниципаль хокукый актлар нигезендә муниципаль берәмлек мәнфәгатьләрен түләүсез нигездә тапшыру;

д) федераль законнарда каралган башка очраклар;

1.2. Түбәндәге эчтәлекле 2.1 пункт белән тулыландырырга:

«2.1. шәхсән яисә ышанычлы затлар аша эшмәкәрлек эшчәнлеге белән шөгыльләнергә";

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмати порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында «Актаныш авыл җирлеге» бүлегендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Совет рәисе,
Актаныш авыл җирлеге Башлыгы Э.Н.Фәттахов